ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме икенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы егерме икенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан 2020 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм әлеге оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча күрелгән чаралар турында мәҗбүри гавами хисабы.
4. «Корал турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
5. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
6. Граждан коралы әйләнеше өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны катгыйландыру зарурлыгы турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгате хакында.

7. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

8. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 31 һәм 150 статьяларына наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше өчен җаваплылыкны катгыйландыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

9. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законның $10^6$ һәм $15^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

10. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

11. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 530-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив хокукый актларны тиз арада кабул итү кирәклеге хакында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгате турында.

12. Норматив-хокукый җайга салуны «Интернет» челтәре, шул исәптән социаль челтәрләр, аша деструктив мәгълүмат таратуны чикләү өлешендә камилләштерү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгате турында.

13. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советынын закон чыгару инициативасы хакында.

14. «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан

Республикасы Законына һәм «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 181-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

15. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 196-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «2020 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 189-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

17. «2020 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 190-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» 191-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 193-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

20. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 194-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

21. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 192-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

22. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 198-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

23. «Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 199-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

24. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 195-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

25. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 197-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

26. «2020 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы доклады.

27. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына Россия Федерациясе Дәүләт чиген саклауда ихтыярый башлангычларда катнашучы гражданнарга ярдәм чараларын камилләштерү мәсьәләсе буенча үзгәрешләр кертү хакында» 1154844-7 номерлы федераль закон проекты турында.

28. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1164301-7 номерлы федераль закон проекты турында (җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкара һәм тышкы икътисадый бәйләнешләрне гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча).

29. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 1171868-7 номерлы федераль закон проекты хакында (финанс базары оешмалары җаваплылыгын билгеләү өлешендә).

30. «Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция житештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү турында» 1163880-7 номерлы федераль закон проекты хакында (муниципаль округларның җирле үзидарә органнарына алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшә территорияләрнең чикләрен урнаштыру хокукы бирү өлешендә).

31. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 1172553-7 номерлы федераль закон проекты турында (банкротлык институтын реформалаштыру өлешендә).

32. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1146599-7 номерлы федераль закон проекты хакында (урман парклары яшел поясларын территорияләрдән махсус шартларда файдалану зоналарына кертү өлешендә).

33. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәреш кертү турында» 1147763-7 номерлы федераль закон проекты хакында (өстәмә вәкаләтләр бирү өлешендә).

34. «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1149512-7 номерлы федераль закон проекты турында (территорияне комплекслы үзләштергәндә, аерым очракларда территорияне межалау проектына үзгәрешләр кертмичә генә җир кишәрлеге булдыру мөмкинлеген билгеләү өлешендә).

35. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү турында» 1160405-7 номерлы федераль закон проекты хакында (хайваннарны карап тотуның гомуми таләпләре исемлеген тулыландыру өлешендә).

36. «Россия Федерациясе Урман кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

37. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1142943-7 номерлы федераль закон проекты турында (сыра һәм сыра эчемлекләрен җитештерү һәм (яисә) аларның әйләнешенә таләпләрне бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

38. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1169750-7 номерлы федераль закон проекты турында (акчалар күчерүне чикләүләрне бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

39. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына корал әйләнеше өлкәсендә дәүләт контролен камилләштерүгә бәйле үзгәрешләр кертү хакында» 1177082-7 номерлы федераль закон проекты турында.

40. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1161234-7 номерлы федераль закон проекты хакында (муниципаль округларның җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен шәһәр округларының җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә туры китерү максатларында).

41. «Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1053866-7 номерлы федераль закон проекты турында (торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган мәгълүмат төрләрен

оптимальләштерү һәм төбәк мәгълүмат системалары статусын билгеләү өлешендә).

42. «Гражданнар оборонасы турында» Федераль законның 18 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1167477-7 номерлы федераль закон проекты турында (гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне яклау буенча җирле әһәмияттәге чараларны тәэмин итү субъектын төгәлләштерү өлешендә).

43. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1183583-7 номерлы федераль закон проекты турында (алимент түләргә бурычлы затларны, балаларын һәм хезмәткә яраксыз ата-анасын карап тотуга алиментларны өлешчә түләгәндә, административ җаваплылыкка тарту мөмкинлеген тәэмин итү максатларында).

44. Хөкүмәт сәгате: «Халыкны сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин итү турында».

45. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2021 елның 11 июне
№ 964-VI ДС